**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӨСЛИМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XIV УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 27**

Мөслим авылы « 09 » июнь 2021 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Советының III чакырылыш LXIV сессиясенең 2019 елның 8 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон, 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталык һәм тәртип кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Советының 2019 елның 8 ноябрендәге 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6 пунктның 31 абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«стационар булмаган сәүдә объекты – инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташу (технологик тоташтыру) булу яки булмауга карамастан, җир участогы белән ныклы бәйләнмәгән вакытлыча корылма яки вакытлыча конструкция, шул исәптән күчмә корылма булып торган сәүдә объекты;»;

1.2. 6 пунктның 43 абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«якын-тирә территория – Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртип нигезендә муниципаль берәмлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре билгеләнгән очракта, бина, корылма, төзелеш, җир участогы янындагы гомуми файдаланудагы территория;»;

1.3. 6 пунктның 61 абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«төзекләндерү элементлары – декоратив, техник, планировка, конструктив җайланмалар, яшелләндерү элементлары, төрле җиһазлар һәм шул исәптән биналарның, корылмаларның, төзелмәләрнең фасадларын бизәү элементлары, кече архитектура формалары, капиталь булмаган стационар булмаган корылмалар һәм төзелмәләр, мәгълүмат щитлары һәм территорияне төзекләндерүнең состав өлешләре буларак кулланыла торган күрсәткечләр.;»;

1.4. пунктта «муниципаль заказны урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге төр эшләрне үткәрүгә конкурста җиңгән» җөмләсен төшереп калдырырга.

1.5. пункттагы 2 пунктчада «муниципаль заказны урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге төр эшләрне үткәрүгә конкурста җиңгән» җөмләсен төшереп калдырырга.

1.6. 45 пунктта «муниципаль заказны урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге төр эшләрне үткәрүгә конкурста җиңүчеләр» җөмләсен төшереп калдырырга.

1.7. 59 пункттагы 1 абзацта «муниципаль заказны урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге төр эшләрне үткәрүгә конкурста җиңгән» җөмләсен төшереп калдырырга;

1.8. 64 пунктта «муниципаль заказны урнаштыру нәтиҗәләре буенча әлеге төр эшләрне үткәрүгә конкурста җиңгән» җөмләсен төшереп калдырырга.

1.9. 116.13 пунктны «(әмма тиешле тәртиптә төзелгән һәм дәүләт кадастр исәбенә куелган җир кишәрлекләренең милекчеләре өчен, әгәр Россия Федерациясе законнарында каралган мәҗбүри таләпләрне бозмаса, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру турында Карар кабул итү мөмкинлеге тулысынча юкка чыгарылырга тиеш түгел)» дигән җөмлә белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында (http://muslumovo.tatarstan.ru) Мөслим авыл җирлеге битендәге мәгълүмати стендта бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Мөслим авыл җирлеге Башлыгы** **Р.Х.Муллин**